# Дуслык һәм хезмәт сөючәнлек турында әкият.

Бер матур урманда кечкенә генә соры өй булган. Анда бер тычкан яшәгән.

Әйе! Әйе! Гади генә бер тычкан булган ул.



Аның дуслары бөтенләй булмаган, ләкин ул рәсем ясап үзенә бер шөгыль таба икән. Бер искиткеч матур язгы иртәдә тычкан йокыдан уянган һәм үзенең өенең тәрәзәләрен ачып куйган. Ул тәрәзә артында табигатьнең кышкы йокыдан ничек итеп уянуын күргән. Кояшның якты нурлары һавада йөзеп йөрүче ак, йомшак болытлар аша үтеп, тирә-якны нурга күмә икән. Тирә- як яшелеккә күмелә, чәчәкләрнең яшь таҗлары шытып килә, алардан чыккан хуш ис башларны әйләндереп бөтен дөньяга тарала. Тычкан урамга чыккан. Шушы матур манзарадан аның шатлыгы эченә сыймаган. Ул үзенә соры төстәге өенә карап торган һәм өен бизәү өчен табигатьтә булган барлык төсләрне дә кулланып карамакчы булган. Өенең түбәсен ул күк төсенә- зәңгәрсу төскә, тәрәзә капкачларын үлән төсенә- яшел төскә буяган, ә өенең үзен буяр өчен кояш төсен сайлаган.

Аның яныннан бер куян узып бара икән.



Ул бу өйне күреп бик аптыраган.

Бик сәер! Ничек мин бу матур өйгә моңарчы игътибар итмәгәнмен икән! ? - дип уйлаган ул.

-Бу өйдә  кем яши?- дип сораган куян.

-Мин рәссам - тычкан булам, ә син кем ?- дип сораган тычкан .

-Мин куян булам!- дигән .

-Ә син нәрсә эшли аласың?

-Мин  бакчачы-куян ! Чәчәкләр,  агачлар  утыртам, бакчаны  карап , тәртиптә тота  алам- дигән ул. Тик  менә  минем  дусларым  юк.

-Әйдә, бергә  дуслар  булып  бергә  яшик!  -дигән рәссам тычкан.

-Әйдә! -дип шатланып,  җавап биргән бакачачы куян.

Алар  бергә-бергә  яши башлаганнар. Куян  бакчага,  ишегалдына  чәчәкләр , агачлар  утырткан.

Табигатьнең  барлык  төсләре  белән  балкып  торучы  өйләре,  тагын  да матурланып,  ямьләнеп  киткән.

Якыннан гына сикереп бака үтеп бара  икән.  Ул кояш шикелле сары матур



өй янында туктап калган.

-Бу өйдә кем яши? – дип сораган бака.

-Бу мин рәссам –тычкан!-дип җавап биргән тычкан.

-Бу мин бакчачы –куян! - дигән куян.

-Ә син кем?- дип сораганнар бакадан.

- Мин пешекче бака булам. Минем иң яраткан шөгылем бар. Мин тәмле ризыклар пешерергә бик яратам. Миңа үзегез белән яшәргә рөхсәт итсәгез, мин сезне гел тәмле ризыклар белән сыйлаячакмын!- дигән бака.

- Без бик шатланып риза булабыз! - дип җавап биргәннәр куян белән тычкан.

Алар барысы бергәләшеп дус, тату яши башлаганнар.

Иртән иртүк йокыдан уяналар икән, бар җирне ялт иттереп чистарталар, тәмле итеп ашарга әзерлиләр, ә кич белән биеп күңел ачалар икән. Бервакыт боларның өйләре яныннан узып баручы бүре туктаган. Бөтен урамга таралган тәмле ризык исеннән ач бүренең башлары әйләнеп киткән.

У-У-У!- дип улап җибәргән ул.

Өйдә яшәүчеләрнең бу бүренең улавы бик куркыткан, кем кая кача ала шунда качкан. Ә бүре ой янына якын килеп сорый башлаган.

-Бу матур өйдә кем яши? Мондый тәмле ризыкларны кем пешерә?,-дип сораган ул.

-Мин рәссам тычкан ,мин бакчачы куян, мин пешекче бака !-дип җавап биргәннәр алар .

-Ә син кем?- дип сораганнар.

- Мин акыллы ,тәртипле бүре! Сез миннән курыкмагыз!Ләкин мин ялгыз , минем дусларым юк!- дигән бүре

Куян ,тычкан ,бака чыкканнар һәм буредән сорыйлар икән :

- Ә син нәрсә эшли beләсең соң ?



-Мин урам себерүче ,урам җыештыручы бүре. Мин сезгә бик яхшы дус булырмын,ишегалдыгызны тәртиптә тотармын -дигән бүре .

-Ярар алайса , әйдә дус-тату булып, бергә яшик, ә хәзер әйдә тәмле итеп пешкән ризыклар белән чәй эчәбез!- дигәннәр алар.

Алар бергәләшеп чәй эчкән арада боларның өй янынннан бер төлке узып бара икән .Ул мондый матур, бизәкле өйне күреп, авызын ачып сүзсез калган.Өй янында матур чәчәкләр , агачлар үсеп утыра икән.Аларга сулар сибелгән , керү юллары, ишегалды чип-чиста итеп җыештырылган икән.

- Монда хуҗалар бармы? Бу матур өйдә кем яши?- дип сораган төлке.

Барлык хайваннар да, рәссам- тычкан,бакчачы-куян,пешекче-бака һәм җыештыручы -бүре,барысы бергәләшеп төлкегә баш иярргә чыкканнар.

-Без барыбызда дус-тату яшибез һәм һәрберебез үзенең эшен яхшы башкара -дигәннәр алар.

-Минем дә сезнең белән дус-тату яшисем килә.Мөмкинме!?- дип сораган төлке.

-Ә син нәрсә эшли беләсең!? -дип сораганнар алар төлкедән.

-Мин оста куллы төлке булам,бәйли ,тегә һәм чигә алам ! Бергә-бергә яшәү күңеллерәк!- дигән ул.

-Әйдәгез!- дип шатланып риза булганнар барысыда.

Алар балта остасы - аюны чакырганнар .Аю өйгә икенче кат төзеп биргән. Нинди матур, зур өебез булды дип куанганнар барысыда.Тычкан буяу эшенә керешкән,куян матур чәчәкләр утырта башлаган ,бүре ишегалдын себергән ,төлке өйгә матур челтәрләр тегә башлаган ,ә бака тәмле ризыклар пешергән .Элек тычкан бер ялгызы гына яшәгән. Хезмәт сөючәнлек һәм һөнәрле булу аркасында үзенә күпме дуслар тапты. Дуслар өйдәге барлык эшләрне эшләделәр һәм биеп күңел ачтылар.

